РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«20» июнь 2019 с. Тюлячи № 373

Теләче муниципаль районы буенча 2019-2020 елларның ягу сезонына әзерләнү буенча чаралар турында

Ростехнадзорның Татарстан Республикасы буенча Идел буе территориаль бүлегенең 2019нчы елның 16нчы маендагы 16472/12 номерлы хатын караганнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131нче номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы буенча 2019-2020 елларның ягу сезонына вакытында әзерләнү һәм аны тотрыклы үткәрү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019-2020 елларның ягу сезонына әзерләнү буенча район штабы төзергә һәм аның составын 1нче кушымта буенча расларга.

2. Районның муниципаль учреждениеләрен, оешмаларны һәм учреждениеләрне 2019-2020 елларның ягу чорында эшләргә әзерләү буенча 2нче кушымта нигезендә чаралар планын расларга.

3. Район штабына:

- Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге белән берлектә район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре комиссияләре нәтиҗәләре буенча энергетик объектларның кышкы шартларда эшләүгә әзерлек паспортларын бирүне оештырырга;

- энергия белән тәэмин итүче оешмалар белән берлектә, җирле бюджеттан финанслана (табигый һәм кыйммәти чагылышта) торган барлык район оешмалары һәм учреждениеләренең 2019нчы елның 1нче сентябренә барлыкка килгән бурычларын исәпкә алып, энергия куллану лимитын аларның нормаль эшчәнлеген тәэмин итәрдәй дәрәҗәдә билгеләргә;

- 2019нчы елның 1нче июленнән 1нче ноябренә кадәр, һәр айның 3нче числосына кадәр, ягу чорында эшләүгә әзерләүнең барышы турында мәгълүматны кушымта нигезендә форма буенча «Торак фонды мониторингы» системасына, һәм атна саен – «Муниципаль берәмлекләрнең ягу чоры» системасына http://ozp.gosnadzor.ru адресы буенча кертергә;

- 2019нчы елның 5нче июленә кадәр экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге Федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе белән җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның, җылылык энергиясен кулланучыларның җылылык белән тәэмин итү чорына әзерлеген бәяләү графигын килештерергә;

- 2019нчы елның 1нче сентябренә кадәр коммуналь хуҗалык оешмаларының мобиль дизель генераторларын, халыкның яшәешен тәэмин итү системалары объектларының өзлексез эшләвен тәэмин итү өчен, эш хәленә китерү буенча чаралар күрергә;

- 2019нчы елның 1нче ноябренә кадәр экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге Федераль хезмәтенең Идел буе идарәсендә җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягу чорына әзерлек актларын Кагыйдәләргә туры китереп алуны тәэмин итәргә;

- 2019нчы елның 15нче ноябренә кадәр муниципаль берәмлекнең ягу чорына әзерлек паспортын алырга;

- 2019нчы елның 15нче сентябренә кадәр әзерлек паспортларын рәсмиләштереп, аларны «Торак фонды мониторингы» системасында урнаштырып, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм социаль объектларны ягу чорына әзерләүне тәмамларга;

- 2019нчы елның 15нче сентябренә кадәр энергетика комплексы объектларын, сәнәгать оешмаларын һәм торак-коммуналь комплексы оешмаларын җылылык белән тәэмин итү чорына әзерләү буенча чаралар планын үтәүне тәэмин итәргә;

- 2019нчы елның 1нче сентябренә кадәр җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның резерв ягулык хуҗалыкларының эш халәтен тәэмин итү һәм аларда резерв ягулыкның кирәкле запасын булдыру буенча чаралар күрергә.

4. Үзләренең котельныйлары һәм җылылык челтәрләре булган район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- 2019-2020 еллар ягу чорына объектларның әзерлеген тикшерү буенча комиссия төзергә һәм комиссия составына Ростехнадзорның Идел буе территориаль бүлеге вәкилен кертергә;

- 2019нчы елның 1нче сентябренә кадәр котельныйларны эш хәленә китерү һәм резерв ягулыкның тиешле запасын булдыру буенча чаралар күрергә;

- 2019нчы елның 1нче августына кадәр 2019-2020 елларның ягу чорына җылылык белән тәэмин итүгә түләүне, уртача тәүлеклек температура һәм ягу чорының дәвамлылыгыннан чыгып, факттагы мәгълүматлар нигезендә яңадан исәпләргә.

5. «Идарәче компания» ҖЧҖкә тәкъдим итәргә»:

- күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр өчен халыктан акча җыю буенча нәтиҗәле эш оештырырга, шул исәптән гражданнарның торак-коммуналь хезмәтләр өчен вакытында түләнмәгән бурычларын каплауга юнәлдерелгән чаралар күрергә;

- күрсәтелгән эш төрләрен башкаруга лицензиясе булган махсуслаштырылган оешмаларны җәлеп итеп, күпфатирлы йортларда төтен һәм җилләтү каналларын тикшерүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

- «Газпром трансгаз Казан» ҖЧҖнә бина милекчеләренең төтен һәм җилләтү каналларын тикшерүдән баш тарту очраклары турында, газ приборларынөзү тәкъдиме бедән, мәгълүмат җибәрергә.

6. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның «20» июненнән
373 номерлы карары белән
расланган

2019-2020 елларның ягу сезонына әзерләнү буенча район штабы составы

Район штабы начальнигы:

| | | |
|---|---|---|
| Хәмидуллин И.Х. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе. |

Район штабы башлыгы урынбасары:

| | | |
|---|---|---|
| Шәрипов М.М. | - | «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 7 отряды» федераль казна учреждениесенең 134 янгын сүндерү-коткару бүлеге начальнигы (килешү буенча). |

Район штабы әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Низаметдинов Р.Х. | - | Теләче муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы (килешү буенча); |
| Валеев Ф.С. | - | Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы; |
| Хаҗиев Р.М. | - | Теләче районы газ эксплуатациясе хезмәте начальнигы (килешү буенча); |
| Галявиев И.Ф. | - | «Энергосбыт»ның Алабуга бүлеге Теләче участогы начальнигы (килешү буенча); |
| Якупов Р.Ш. | - | Алабуга «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы - Теләче районы электр челтәрләре начальнигы (килешү буенча); |
| Хәбибуллин И.И. | - | Ростехнадзорның ТР буенча Идел буе территориаль бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Рахимуллин Т.М. | - | Ростехнадзорның ТР буенча Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы (килешү буенча); |
| Нуриев З.Д. | - | Ростехнадзорның ТР буенча Идел буе территориаль бүлеге баш дәүләт инспекторы (килешү буенча); |
| Шәмсетдинов И.М. | - | Ростехнадзорның ТР буенча Идел буе территориаль бүлеге дәүләт инспекторы (килешү буенча). |

Кушымта № 2
Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның «20» июнендәге
373 номерлы карары белән
расланган

Теләче муниципаль районы предприятиеләрен һәм оешмаларын 2019-2020 елларның ягу сезонына әзерләнү буенча чаралар планы

| № п/п | Чаралар исеме | Үтәү вакыты | Җаваплар |
|---|---|---|---|
| 1. | Предприятиеләрне, оешмаларны, учреждениеләрне 2019-2020 елның ягу чорына әзерләү буенча, эшләр исемен, күләмен, үтәү срогын һәм җаваплыларны күрсәтеп, чаралар планы эшләргә | 10.07.2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 2. | 2018-2019 елның ягу чоры вакытында ачыкланган җитешсезлекләрне исәпкә алып, предприятиеләрнең, оешмаларның җылылык хуҗалыгына план буенча ремонт үткәрергә | 15.08.2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 3. | Газ сыман ягулыкта эшләүче җиһазларга хезмәт күрсәтүче персоналны укытуны һәм аттестацияләүне үткәрергә | 20.08.2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 4. | Газсыман ягулыкка күчмәгән предприятиеләр, оешмаларның ягулык чорында өзлексез һәм авариясез эшләүләре өчен кирәкле күләмдә каты ягулык (ташкүмер, утын) әзерләргә | 15.09.2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 5. | Төп ягулык сыйфатында газ кулланучы предприятиеләргә һәм оешмаларга, авария яки газ-транс-порт системасы эшенең технологик режимыбозылу нәтиҗәсендә газ бирүне чикләү очрагына, резерв ягулык запасы булдырырга | 01.10.2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 6. | Предприятиеләр, оешмалар тарафыннан ягулык чорына әзерлек буенча чаралар үтәлешен тикшерергә | Атна саен 15.09.2019 кадәр | Район штабы |
| 7. | Газ котельнаясы операторының эш урынында булырга тиешле инструкцияләрне, куркынычсызлык кагыйдәләрен һәм башка мәгълүмати-техник документацияне, шулай ук җиһазлардагы күрсәткечләрне, табличкаларны яңартырга. Приказ белән газ хуҗалыгын эксплуатацияләү өчен | 01.08.2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | җаваплыларны билгеләргә | | |
| 8. | Контроль-үлчәү приборларына (газ тотылуын исәпләгеч, манометрлар, термометрлар) тикшерү үткәрергә | 25.08.2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 9. | Бинаның ишек-тәрәзәләренә ремонт үткәрергә. Җылылык һәм энергия саклау буенча чараларны үтәргә | 15. 09. 2019 | Предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр җитәкчеләре |
| 10. | Предприятиеләр һәм оешмаларның җылылык хуҗалыгын, ягу сезонына әзерлеге турында акт-паспортлар биреп, кабул итүне оештырырга | 01.09.2019дан 15.09.2019 кадәр | Район штабы |